КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Республиканское агентство по печати
и массовым коммуникациям
Декабристов ул., 2, г.Казань, 420066

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ
Республика матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләр агентлыгы
Декабристлар ур., 2, Казан шәһәре, 420066

Тел.: (843)570-31-22, факс:(843)537-91-04, ra.tatmedia@tatar.ru, tatmedia.tatarstan.ru

ПРИКАЗ　　　　　　　　　　　　　　　БОЕРЫК

2015 елның 14 августы, № 27/1-п

«Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына кергән гражданнар һәм оешмалар мөрәҗәгатьләренә анализ ясау тәртибен раслау турында

«Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясы нигезендә боерык бирәм:

1. «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына (алга таба – Агентлык) кергән гражданнар һәм оешмалар мөрәҗәгатьләренә анализ ясау тәртибен расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Гомуми бүлек (Казаченко Т.Е), яртыеллыкның соңгы аеннан соң килүче айның 15 числосыннан да соңга калмыйча, Агентлыкка кергән гражданнар һәм оешмалар мөрәҗәгатьләренә анализ ясарга тиеш.

3. Җитәкче, җитәкченең беренче урынбасары, җитәкче урынбасары гражданнарны кабул итү вакытында алынган мөрәҗәгатьләр турындагы мәгълүмат хисап аеннан соң килүче айның 10 числосыннан да соңга калмыйча эшләр идарәсе башлыгы (Хайдаров Л.И) тарафыннан Агентлыкның гомуми бүлегенә тапшырылырга тиеш.

4. Матбугат хезмәтләре һәм җәмәгатьчелек белән элемтәләр бүлеге башлыгы (Гарифуллина Р.Р.) гражданнардан һәм оешмалардан килгән мөрәҗәгатьләргә анализны Агентлыкның рәсми сайтындагы «Гражданнар мөрәҗәгатьләре һәм аларны кабул итү» бүлегендә яртыеллыкның соңгы аеннан соң килүче айның 15 числосыннан да соңга калмыйча урнаштыруны тәэмин итәргә тиеш.

5. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Җитәкче урынбасары Э.Ф. Әхмәтовага йөкләргә.

Җитәкче　　　　　　　　　　　　　　　А.Р. Зарипов

«Татмедиа» республика матбугат
һәм массакүләм коммуникацияләр
агентлыгы җитәкчесенең
2015 елны 14 августындагы
27/1-п номерлы боерыгы белән
расланды

**«Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына кергән гражданнар һәм оешмалар мөрәҗәгатьләренә анализ ясау тәртибе**

1. Әлеге Тәртип «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясы нигезләмәләрен үтәү максатыннан эшләнде һәм «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына (алга таба – Агентлык) кергән гражданнар һәм оешмалар мөрәҗәгатьләрен гомумиләштерү һәм анализлау тәртибен билгели.

2. Мөрәҗәгатьләрне гомумиләштерү һәм анализлау, электрон документ әйләнешенә һәм әлеге тәртипнең 3 пункты нигезендә бирелә торган мәгълүматка таянып, Агентлыкның гомуми бүлеге (алга таба – Бүлек) тарафыннан башкарыла.

3. Бүлеккә Җитәкче, җитәкченең беренче урынбасары, җитәкче урынбасары (алга таба – Агентлык җитәкчелеге, гражданнарны шәхси кабул итүгә вәкаләтле затлар) гражданнарны шәхси кабул итү вакытында алынган мөрәҗәгатьләр турындагы мәгълүмат гражданнарны Агентлык җитәкчелеге тарафыннан шәхси кабул итүне терки торган эшләр идарәсе башлыгы тарафыннан тапшырыла.

4. Әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән мәгълүмат Бүлеккә эшләр идарәсе башлыгы тарафыннан хисап аеннан соң килүче айның 10 числосына кадәр тапшырыла.

5. Бүлек башлыгы 2 пунктта күрсәтелгән мәгълүматны, шулай ук әлеге Тәртипнең 3 пункты нигезендә кергән мәгълүматны яртыеллыкның соңгы аеннан соң килүче айның 15 числосыннан да соңга калмыйча гомумиләштерә һәм анализлый.

6. Агентлыкка кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау нәтиҗәләре буенча Агентлыкта гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү турында аналитик белешмә рәсмиләштерелә.

7. Аналитик белешмәдә (хисап чоры өчен) түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш: Агентлыкка кергән, башка адреска җибәрелгән һәм каралган язма мөрәҗәгатьләрнең, электрон документ рәвешендәге мөрәҗәгатьләрнең саны, гражданнарны кабу итү урыннары, көннәре һәм сәгатьләре, шәхси кабул ителгән гражданнарның саны, гражданнарны шәхси кабул итүгә вәкаләтле затлар һәм урыннарга чыгып үткәрелгән кабул итүләр турында белешмәләр, мөрәҗәгатьләрнең тематикасы, мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре буенча кабул ителгән чаралар, шул исәптән кабул ителгән норматив хокукый актлар һәм башка актлар (булган очракта) хакында белешмәләр, шулай ук узган елның шул чоры белән чагыштыру.

8. Анализ нәтиҗәләре Агентлык җитәкчелеге киңәшмәсендә карала һәм хезмәт эшчәнлеген планлаштырганда исәпкә алына, шулай ук мөрәҗәгатьләр белән эшләүнең нәтиҗәлелеген, мөрәҗәгатьләрне карау срокларын тикшереп торуның сыйфатын арттыруга ярдәм итә торган чаралар исемлеге булдырыла.

9. Мөрәҗәгатьләр анализы, Агентлыкның рәсми сайтына урнаштыру өчен, матбугат хезмәтләре һәм җәмәгатьчелек белән элемтәләр бүлегенә җибәрелә.

10. Агентлыкка кергән гражданнар мөрәҗәгате ачык мәгълүмат булып тора, яртыеллыкның соңгы аеннан соң килүче айның 15 числосыннан да соңга калмыйча Агентлык сайтына урнаштырыла http://tatmedia.tatarstan.ru/.